**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы һәм 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составына Шәрифуллин Марат Дамир улын – Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банк идарәчесен (килешү буенча) кертергә;

б) Комиссия әгъзасы А.Р. Шәфигуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 21 февраль
№ ПУ-140